Сабантуй бүген бездә...

(Бакчабызда үткәрелгән бәйрәм сценариясе)

Максат: балаларны татар милли милли мәдәнияте белән таныштыру,аларда борынгы гореф – гадәтләргә ихтирам тәрбияләү,татар халкының милли бәйрәмнәренә, җырларына, уеннарына кечкенәдән мәхәббәт тәрбияләү.

Сабантуй булачак уен мәйданы бәйрәмчә бизәлә.Озын колгага чигүле сөлгеләр,яулыклар,төрле төстәге шарлар эленә.Уеннар оештырыла торган урыннар тиешенчә җиһазландырыла.Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән бирнә җыю оештырыла.Бирнәләр җыелып беткәннән соң бәйрәм музыкасы астында балалар үз урыннарына чыгып басалар.Уртада бәйрәмне алып баручы тәрбияче.Мәйданның ике ягына иңнәренә бизәкле чиләк-көянтәләр элгән кызлар узалар.Җыйган бирнәлрне колгага бәйләп күтәргән малайлар мәйданны әйләнәләр.

Алып баручы: Ишетегез,күрегез,
Сабантуй килә.
Илләр буйлап килә-килә
Безнең бакчага килеп җитә.

Әмир: Сабантуй,сабантуй,
Сабантуй гөрләп килә.
Килегез, дуслар кунакка,
Сабантуй бүген бездә.

Бала : Җилферди чиккән сөлгеләр,
Бүләкләр күбебездә.
Көрәшик тә, узышыйк та,
Сабантуй бүген бездә.

Бала : Күңелле сабан туйлары,
Бүген бәйрәм,зур бәйрәм,
Матур җырлар җырлый – җырлый,
Уйныйбыз әйләп – бәйләп.(Г.Зәйнәшева сүзләре).

Сагитова Ралина сезне үзенең “Кояш нурлары” дигән җыры белән сәламли.

Күмәк җыр. “Сабан туе – хезмәт туе”(татар халык көе,М.Садри сүзләре.)

Алып баручы: Хәерле көн,кадерле балалар,тәрбияче апалар,әти-әниләр, кунаклар! Без сезне бүгенге иң матур, иң күркәм бәйрәмебез белән кайнар котлыйбыз.Сабан туе ул – хезмәт, дуслык, шатлык, җыр, бию, осталык бәйрәме.Сабантуй – вакыт чоңгылында югалмаган, үзенең тәмен, ямен безнең көннәргә кадәр җиткерә алган бәйрәм ул.Рөхсәт итегез бәйрәмне ачып җибәрү һәм бәйрәм белән тәбрикләүөчен сүзне бакчабыз мөдире Сиренә Нургаян кызы Хабибуллинага сүз бирелә.

Татарстан Республикасы гимны уйнатыла.Сабантуй әләме күтәрелә.

бала: Татарстан – үз илебез,
Безнең туган җиребез.
Шушы газиз җиребезнең,

Балалары инде без.
Бала : Татарстан – үз илебез,
Безнең якты өебез.
Янығыз да, көегез дә,
Илебезне сөегез.
Бала : Дөньяда иң – иң матур ил.
Ул минем туган илем,
Дөньяда иң – иң матур тел ,
Ул минем туган телем. (Р.Миңнуллин сүзләре).
Күмәк җыр. “Әнисә”.
Лирик бию “Сөлге чигәм”.(Уртанчылар төркеме кызлары белән).

Бала : Без уйныйбыз – уйныйбыз,
Якты көннән туймыйбыз.
Сабан туе гөрләп торсын,
Җырлыйбыз да , биибез.
бала: Төрле уеннар башлана,
Җитешсәң барын күреп,
Катнашасың килсә катнаш,
Мәйдан эченә кереп.
Бала : Сабантуенда уеннар,
Күп була, төрле була.
Уеннарсыз Сабантуе –
Булмаган да күк була.
“Кәрия – Зәкәрия”(татар халык көенә).Җырлы бию.(Зурлар төркеме балалары белән).
Бала : Җыр – биюсез бер бәйрәм узмый,
Шуны белегез,
Балаларыбыз бик булганнар,
Ә сез карап китегез.
Бала : Бүген бездә Сабантуй,
Эшләреңнен барын куй.
Тизрәк йөгер мәйданга,
Бәйрәм башлана анда.(Ф.Яруллин сүзләре).
Бала : Чәчәккә күмелгән тугайлар
Июньнең иң матур көнендә.
Бакчаның иң матур җирендә
Сабантуй, килегез күрергә! (Э.Мөэминова сүзләре).
Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары чыгышы.”Әйлән – бәйлән” (Р.Миңнуллин сүзләре).**Җырлы бию.**

бала: Илләребез тыныч булсын,
Ә Сабантуй – мөбәрәк!
Үзебез таза – сау булыйк,
Бәхетебез түгәрәк.

Бала : Без уйныйбыз Сабантуйда
Матур уеннар сайлап.
Безнең уенга кушылып,
Кошлар торалар сайрап.
Бала : Күбәләкләр безнең белән
Уйныйлар әйләп – бәйләп.
Сабантуй ул һәркем өчен
Көтеп алынган бәйрәм.
Мәйданга башлангыч сыйныфта укчы,көрәш түгәрәгенә йорүче ике малай керә.Аларга Камырша һәм Батырша дигән исемнәр бирәбез.
Камырша: - Исәнмесез, балалар! Исәнмесез кунаклар! Таныш булыйк мин – Камырша, ә бу егет минем дустым Батырша.Безнең дә Сабантуй уеннарында катнашасыбыз килә.
Алып баручы: Әйдәгез,әйдәгез, кунаклар түрдән узыгыз!Без кунакларны бик яратабыз.Сез бит мәктәбебезнең горурлыгы.Әле кайчан гына безнең бакчада йөрдегез.Кечкенәдән спортны яратып үстегез.Әйдәгез үзегезнең сәләтләрегезне ,көчегезне безгә дә күрсәтегез әле.(Камырша белән Батырша көрәшәләр.Аннары көрәшне балалар дәвам итә.)
Алып баручы:Уеннарыбызны башлыйбыз.Кем җитезрәк? Кем тизрәк? Бу мәйданга кил тизрәк!
1 уен.Чүлмәк вату уены уйныйк әле.

Алып баручы:Чүлмәк ватам, чүлмәк ватам,
Ватып булырмы икән?
Бүләккә бер чиккән яулык,
Алып булырмы икән.
2 нче уен. “Су ташу”.
Алып баручы: Менә сиңа сулы чиләк,кашыклар ал кулыңа.
Йөгер тизрәк,иң алдан кил, егыла гына күрмә.
3 нче уен.”Капчык киеп йөгерү”.
Алып баручы: Икегезгә ике капчык,ягез әле тотыгыз!
Сабантуенда ярышып,сез дә бүләк алыгыз!
Кемнәр өлгер,кемнәр җитез,минем янга килегез!
Әйдә карыйк ярышып,капчык киеп чабышып.
4 нче уен.”Кашыкка йомырка салып йөгерү”.
Алып баручы: Кашык кабып йөгерәм дип,мактанырга ашыкма.
Син менә йөгереп кара, йомырка салып кашыкка.
5нче уен.”Атлар чабышы”.
Алып баручы:Малайлар алып килгәннәр иң җитез юртакларны.
Үзләре дә сынатмыйлар, читтә торсын атлары.
Йола буенча иң азактан килгән “атка” чиккән сөлге бирелә.
Уеннардан соң мәйданга 4 бала чыга.Кулларында шарлар.
бала: Сабан туе,сабан туе,
Без бакчада уйныйбыз.
Ярышабыз,узышабыз,

Матур җырлар җырлыйбыз.

бала: Иң өлгерләр,иң җитезләр,
Бүләк яулап алалар.
Һәр төркемнән җыелганнар
Сабантуйга балалар**. (Р.Корбан сүзләре).**

Бала : Сандугачкай, сайра ,сайра.
Котлап җәйге таңнарны.
Туган җирдәй гүзәл җирләр
Дөньяда тагы бармы?

Бала : Күрче, дөнья нинди матур,
Тирә –ягың гөл генә.
Гөлбакчадай ямле була
Бары туган җир генә. **(Р.Вәлиева сүзләре).**

(Шарларны һавага очырталар).

Алып баручы: Дуслар! Көтеп алган Сабан туйлар ахрына якынлашты.Барыбызга да саулык,сәламәтлек,шатлык, куанычлар телим.Илләребез имин булып,киләсе Сабан туй бәйрәмнәрендә дә очрашырга язсын! Сау булыгыз!

Сабантуй бәйрәме “Мин яратам сине, Татарстан” күмәк җыр белән тәмамлана. (Р.Андреев көе, Р.Рәкыйпов сүзләре).